# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ТИМОШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

№ 4 04.11. 2024 ел

«Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге
Ерепкино торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Иске Тимошкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегенең Ерепкино торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 13 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегенең Ерепкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Украинада махсус операциядә катнашучы мобилизацияләнгән затлар , аларның гаиләләреннән һәм көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2025 елда үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә бер тапкыр түләүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы? :

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кышкы карап тоту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык - майлау материаллары сатып алу, торак пункт чикләрендә вак таш белән капланган юл полотносы урнаштыру, юлларны ремонтлау, вак таш, ВКПС, су үткәрү торбалары сатып алу, эшләр өчен түләү-грунт күтәрү, вак таш сибү).

2.Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын йөртүчеләрнең хезмәт хакы);

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар жыенын Татарстан Республикасы Аксубай районы Ерепкино авылының Краснопартизанская ур., 25а йорт адресы буенча урнашкан кибет янында уздырырга.

4. Әлеге карарны» Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында " түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең күпләп җыела торган урыннарына, стендларга һәм такталарга белдерүләр элү юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук Аксубай муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

5.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы: П.А.Мулеева